СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

*5 август, 1998 ел.*
**ЧӘРШӘМБЕ**

*Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.* | № 88 (8245) | *Бәясе билгеләнгәнчә*

## ҮЗӘКТӘ - САБАН АШЛЫГЫ ҺӘМ...

### "Уңыш - 98" матбугат үзәге хәбәр итә

Район хуҗалыклары уҗым культураларын урып - җыюны төгәлләп бетереп киләләр дисәк тә була. Дөрес, берничә хуҗалыкта, аерым алганда, "Чулпан"да, "Таң"да, "Кондырча"да, "Алга" һәм "Агрохимсервис" ярдәмче хуҗалыгында көзге культураларны уру белән сугу арасында бераз аерма бар әле. Арыш һәм уҗым бодаеның уңышына килгәндә, әлегә ул "Сөлчә" һәм "Кондырча"да чагыштырмача югары, "Родина", "Комбайн", Хафизов исемендәге һәм Мичурин исемендәге хуҗалыкларда да елына күрә ярыйсы гына.

Шуңа күрә дә уҗым культураларын чәчеп калдыруга быел игътибарны тагын да күбрәк бирергә кирәклеге аңлашыла. Көннәр ничек кенә коры торса да, барыбер яхшыга өметләнергә кирәк, димәк,уҗым чәчү өчен җирләр әзер булырга тиеш. Район буенча әзер мәйданнар планлаштырылганның яртысыннан артык инде. Шикәр заводы һәм "Агрохимсервис" ярдәмче хуҗалыкларында, "Рассвет"та, "Родина"да һәм кайбер башка хуҗалыкларда андый мәйданнар шактый ишле. Ә менә Муса Җәлил исемендәге, "Чирмешән", "Чулпан"да, "Татарстан"да, РСУ ярдәмче хуҗалыгында бу план яртылаш та үтәлмәгән әле, "Заветы Ильича", Кузнецов исемендәге һәм кайбер башка хуҗалыкларда да тиешленең яртысы кадәр генә.

Җир әзер булмау гына җитмәгән, күпчелек хуҗалыкларда чәчүлек материалның сыйфаты турында рәтләп кайгырту сизелми. Инде көзге чәчүгә тотыныр көннәр килеп җитсә дә, күпчелек хуҗалыклардан орлыклык материалның күчмә фондын да дәүләт орлык инспекциясенә чәчү алды тикшертүенә китермәгәннәр. Ә бит "Татарстан", "Киекле", "Игенче", "Чулпан" кебек хуҗалыкларда андый фонд меңәр центнер, ул берничә партиядә һәм аларны тиз гене тикшереп чыгуы да авыр булачак. Икенчедән, орлыкларын тикшерткән хуҗалыкларда да, аерым алганда Муса Җәлил исемендәге, Хафизов исемендәге, "Үрнәк" хуҗалыкларында орлыкның шактый өлеше тишелеше буенча, кайберләрендә чисталыгы буенча кондициясез булып чыгуы башкаларны да сагайтырга тиештер.

Хәзер район җитәкчелеге, авыл хуҗалыгы һәм азык- төлек идарәсе уҗым культураларының югары уңыш бирүчән һәм югарырак репродукцияле сортларын кайтарту мәсьәләсен кайгырта, әмма хуҗалыкларның үзләрендә дә чәчүлек материалны тиз арада эш итеп кую өчен чынлап торып эшләргә тиешләр.

Бу таләп сабан ашлыгы орлыкларын салып кую мәсьәләсенә дә бердәй дәрәҗәдә кагыла. Ә сабан ашлыгын урып- җыюга керешкән хуҗалыклар күп инде. "Рассвет", Синдряков исемендәге, "Татарстан" "Игенче", Мичурин исемендәге хуҗалыклар борчакны, беренчесе, шулай ук "Комбайн" һәм шикәр заводы ярдәмче хуҗалыгы арпаны, мичуринлылар солыны шактый мәйданнарда урып, "Рассвет"та, Синдряков исемендәге һәм шикәр заводы ярдәмче хуҗалыгында аларны йөзәр гектарда суктырдылар да инде. Хафизов исемендәге хуҗалык беренчеләрдән булып сабан бодаен суктыра башлады. Шунысы куанычлы, "Рассвет" һәм Синдряков исемендәге хуҗалыкларда борчак елына күрә әйбәт уңыш бирә.

Терлек азыгы хәзерләү эше дә икенче чиратка куелмый. Кичәге көнгә барлык тупас һәм сусыл азыкларны да кертеп бер шартлы терлеккә тупланган азык запасы 8 центнер азык берәмлегеннән артып китте. "Дуслык"та бу күрсәткеч 16,4, "Кондырча"да 14,3, Заря"да 13,5 центнер.

### Урак батырсыз узмас

МТСның җыелма отрядыннан "Кейс" комбайнчысы **Вячеслав УЛЬДЯКОВ** бу сезонда 3265 центнер, **Хәлим ИБРАҺИМОВ** 3160, **Фәнис ГАЯЗОВ** 2322 центнер ашлык суктырдылар.

***

**"Родина"**дан **Николай МАТВЕЕВ**ның "ДОН -1500" комбайны белән суккан ашлыгы 2200 центнердан артык.

***

**"Киекле"**дән **Салават ӘХМӘТОВ**, К - 701 тракторы белән бер көндә 22 гектарда туңга сөреп, смена нормасын 260 процентка үтәгән.

***

Шул ук хуҗалыктан **Рифкать СӘГЫЙРОВ** ЖРБ -4,2 ле "Нива" белән берьеллык үләннәр чаптыруда смена нормасын 140 процентка үти.

***

**"Игенче"**дән **Әхәт ИБРАҺИМОВ** "ДОН" белән икенче мең центнерга исәп ачты.

***

**"Тәрнәс"**тән **Виктор РЯБОВ** елдагыча "Полесье" белән эшли, смена нормасын 120 процентка үтәп барып, быел 1300 гектардан артык мәйданда үлән чаптырган инде.

***

**"Чулпан"**нан **Владимир НИКИТИН** ДОН белән бодай суктыруда смена нормасын 145 процентка үти, быел суктырган ашлыгы 1380 центнер.

***

**"Комбайн"**нан **Илсур ХӘЙДӘРОВ** туфрак әзерләүдә смена нормасын 120 процентка башкара.



"Дуслык" хуҗалыгында Җирҗизовларның зур гаиләсе төп эшче көчне тәшкил итәләр. Гаилә башлыгы Вәгыйзь ага һәм ике улы тракторчы һөнәрен сайласалар, Фәнис машинаны хуп күрде. Биш еллап инде ул хуҗалыкның "Волгарь" автобусын йөртә, пассажирларның ышанычын, җитәкчелекнең хөрмәтен күптән яуларга өлгерде. Шофер егет машинасын карап йөртә, юл иминлеге кагыйдәләре дә - аның өчен закон, өстәвенә, төгәллеге дә сокланырлык. Шуңа Фәнис Җирҗизов исеме, барлык туганнарыныкы төсле үк, һәрчак уңай яктан телгә алына.

*Рәсемдә: "Дуслык" хуҗалыгы шоферы Ф. Җирҗизов.*

**Н.АЗИЗОВ фотосы**

*Татарстан Президенты М.Ш.Шәймиев:*

## "УРАК ӨСТЕ БЕР МИНУТ ТА КӨТЕП ТОРА АЛМЫЙ"

**Инде хәбәр ителгәнчә, 27 июльдә Казанда Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев министрлык һәм ведомстволар җитәкчеләре, шәһәр һәм район хакимиятләре башлыклары, республиканың эре предприятиеләре һәм банклары җитәкчеләре, Президент, Дәүләт Советы, Министрлар Кабинеты аппаратларының җаваплы хезмәткәрләре, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашында киңәйтелгән киңәшмә үткәрде. Ул авылның кичектергесез проблемаларына, шулай ук социаль мәсьәләләргә багышланды.**

"Урак өсте бер минут та көтеп тора алмый" - Минтимер Шәриповичның бу сүзләре сөйләшүгә эшлекле тон бирде.

**(Ахыры икенче биттә).**

## ХАКИМИЯТ БАШЛЫГЫНЫҢ РӘХМӘТЕ ҖИТКЕРЕЛӘ

Комбайнчыларыбыз бүген бар булган ашлыкны югалтуларсыз җыеп алу нияте белән фидакарьләрчә эшлиләр. Елдагыча, быелгы уракның да үз батырлары бар. Аларга быел да район һәм шәһәр хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллинның намуслы хезмәтләре өчен рәхмәт белдергән, тазалык - саулык, гаилә иминлеге, бәхет теләп язылган хатлары тапшырыла. Августка кергәч, андый рәхмәт хатларын Синдряков исемендәге хуҗалыктан П.И.Варламов һәм С.М.Черепанов, "Киекле"дән Р.А.Сафин алды инде.

Котлау хатлары комбайнчылар һәм башка кыр батырларына эш урынында ук тапшырыла.

## *ИНДЕ БОДАЙГА КҮЧТЕЛӘР*

Бүген "Рассвет"та комбайннар борчак һәм сабан бодае кырларында эшлиләр. 120 гектарда теземнәргә салынган сабан бодаеның 30 гектары суктырылды инде. Уракта элеккечә үк комбайнчылар Фәнис Төхфәтуллин һәм Талип Гобәйдуллин аеруча тырышып эшлиләр.

**Ә.МАНЯПОВА.**

Эссе!

## САБЫР ИТЕГЕЗ!..

**Быелгыдай эссе җәйдән бар тереклек алҗыды. Яңгыр, эсселекнең төшкәнен көтәбез. Берәр өметле хәбәр булмасмы дип, Чулпан метеостанциясенә шалтыратабыз.**

**Станция агротехнигы И.Тафеев безгә түбәндәгеләрне хәбәр итә.**

- Әйе, быелгыдай эссе җәй күптәннән күзәтелмәде. Соңгы шуңа охшаш эсселек 1981 елда теркәлгән иде. Быел июльнең III декадасында нәтиҗәле температура суммасы 1770 градуска җитте,ә норма буенча ул 1579 градуска тигез. Безнең төбәктә иң югары температура да быел булды. 22 июнь көнне эсселек 37,9 градуска җитте. Аңа кадәр максималь температура дип + 37 градусны саный идек, ул 1981, 1984нче елларда теркәлгән булган.

Иваннан август аена прогноз белән кызыксынабыз.

- Август уртасына кадәр шундый эсселек көтелә, аннан яңгырлар башланырга тиеш,- ди агротехник.

Бераз сабыр итәсе бар икән әле халыкның, табигатьнең...

**С.НУРУЛЛИНА.**

## СӨЕНЕЧКӘ ДИСӘК,...

"Үрнәк" КХАсыннан сөт - май комбинатына китерелгән продукция, югары ачылыкта булу сәбәпле, берничә тапкыр кире борылды.

- Июльнең соңгы декадасында гына да шундый продукция 1700кг. тәшкил итте, шул сәбәптән хуҗалык 1513 сум акчасын җилгә очырды,- диделәр безгә авыл хуҗалыгы продукциясе әзерләү һәм сыйфат буенча дәүләт инспекциясе хезмәткәрләре.

Сәбәбе - мәгълүм: суыткыч өзеклекләр белән эшли, сөт блогында чисталык җитенкерәми, санитария таләпләре үтәлми...

Быел сөт җитештерүне узган ел белән чагыштырганда көнгә 2,4 кг. га арттырып куандырган "Үрнәк" икенче яклап үзенә үк зыян ясады да куйды. Ваемсызлык аркасында, нәкъ җырдагыча килеп чыкты :"Сөенечкә дисәк, көенечкә икән..."

# "УРАК ӨСТЕ БЕР МИНУТ ТА КӨТЕП ТОРА АЛМЫЙ"

(Ахыры. Башы 1нче биттә).

Кыр эшчәннәре быелгы уңышны үстерүгә максимум тырышлык куйдылар, осталыкларын кызганмадылар. Әмма, кызганычка каршы, моңарчы күрелмәгән корылык аркасында, эшнең нәтиҗәсе куелган хезмәткә тәңгәл килми, диде докладчы - республика авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек министры Валерий Васильев. Ул Татарстан авыл хуҗалыгындагы хәлнең торышына киң анализ ясады.

Көзге культуралар һәркайда берьюлы өлгерде, бурыч аларны 1 августка кадәр җыеп алудан гыйбарәт. Бүгенге көндә 116 мең гектар бөртекле культуралар урылды. Министр шуңа басым ясап сөйләде: кызганычка каршы, күпчелек хуҗалыклар әлегә хезмәт җитештерүчәнлеген бик акрын арттыра баралар. Әгерҗе, Саба, Менделеев районнары хуҗалыклары игеннәрне уруга бик соң керештеләр. Авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек министрлыгының исәпләвенчә, игеннәрнең бер көн урылмый торуы һәр мең гектардан 20 тоннага кадәр ашлыкны югалтуга китерә.

Быелгы урак өсте игенчегә аерым шартлар куя. Игеннәрнең кыска булуы аркасында ургычларны тиешенчә көйләү, комбайннарны герметиклаштыру таләп ителә. Барлык комбайннарны ике механизатор белән тәэмин итәргә, ә хезмәткә түләүне ашлыкның контроль чыгышы белән бәйләргә кирәк.

Төп товарлы культура - бодай. Безнең алда 600 мең тонна өченче категорияле азык - төлек бодае сату бурычы тора. Министр хуҗалыкларның зур кредитка батуларын әйтеп узды - 800 мең тонна ашлык бәрабәренә ягулык, авыл хуҗалыгы техникасына запас частьләр, кукуруз орлыгы сатып алынды. Өченче категорияле бер тонна ашлыкның бәясе төзелгән килешүләр буенча 715 сум итеп билгеләнде. Җәйнең коры килүен исәпкә алып, Хөкүмәт дәүләт заказын каплау исәбенә ындыр табакларыннан элеваторга кадәр ашлыкны ташу чыгымнарын үз өстенә алды. Җәйнең коры килүен исәпкә алып, ашлыкны сатып алу бәясен күтәрергә булмыймы соң? - дигән сорауга бер мәгънәле җавап алынды: юк, алай иткәндә, Татарстан икмәге бәясе буенча конкуренциягә сәләтле булмаячак.

Бүген дәүләтнең авыл хуҗалыгына чикләнмәгән кредитлар бирү мөмкинлеге булмавы турындагы фикер сөйләшүдә кызыл җеп булып сузылды. Авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек министрлыгы авыл хуҗалыгы техникасына булган запас частьләр буенча мониторинг үткәрде. Республикада кирәкле бөтен нәрсә бар, әмма бөтенесе өчен түләргә кирәк. Ягулык - майлау материаллары, ашлама, чәчүлек орлык - аларның һәркайсы килешүләр буенча гына тәэмин ителә, ә исәп - хисап ясау төре төрлечә булырга мөмкин. Ныклы экономия, булганнарыннан рациональ файдалану, һәр хуҗалыкта ныклап уйланган экономика кирәк - көн таләпләре менә шундый. Киңәшмә барышында Президент М.Шәймиев бу хакта берничә тапкыр кабатлады.

Киңәшмәдә авылга кредит биргән предприятиеләр һәм хәзерләү оешмалары җитәкчеләре дә кул куелган договорларны үтәү өчен югары җаваплылык хисе тоеп сөйләделәр. Һәр тонна ашлыкның үз хуҗасы бар, товар кредиты договорда күрсәтелгән культуралар белән кире кайтарыла.

Бу ел игенчеләр өчен катлаулы булды, корылык уңышның өчтән бер өлешен юк итте, аның каравы, ничек эшләргә кирәклеген өйрәтте. Хәзер бөтен көчне урып - җыю эшләрен уңышлы үткәрүгә тупларга кирәк. Хуҗалыкларның кредит өчен исәп - хисап ясый алулары әнә шуңа бәйле. Соңгы исәптә халыкның икмәк белән тәэмин ителүе дә шуңа бәйле булачак. Узган елгы уңыш запасын исәпкә алсак, тулаем фаразыбыз оптимистик рухта.

Корылык булу сәбәпле, хуҗалыкларны 1999 елгы уңыш өчен сабан культуралары орлыгы белән тәэмин итү мәсьәләсе алга бик нык килеп баса. Яңа, югары уңыш бирә торган культураларны кертү, һава шартларыннан максималь файдалану, матди кызыксындыру чараларын оста куллану, шулай ук 3 процентлы орлык фондының гамәлдә булуы туктатылуы уңаеннан, ел саен чәчүлек орлык туплауның яңа шартларын билгеләү уңыш китерергә тиеш.

Аннары докладчы көзге культуралар чәчүне оешкан төстә үткәрү кирәклегенә тукталды - быел аларны 750 мең гектарга чәчәргә кирәк; туңга сөрү дә игътибар үзәгендә булырга тиеш.

В.Васильев үзенең докладында терлекчелек өчен азык туплау проблемасына тулы тукталды. Аның фикеренчә, сусыл һәм тупас азыклар белән проблема булмаячак. Бүгенге көндә һәр шартлы терлеккә 6,6 центнер азык берәмлеге әзерләнде. Терлек азыгы җитештерү структурасын үзгәртүгә бик җентекле якын килү зарурлыгына аерым басым ясалды. Районнарның күпьеллык үләннәргә, бигрәк тә кузаклылар, рапс, люцерна һәм судан үләннәренә нык исәп тотулары яхшы нәтиҗә бирә. Азык җитештерүнең үзкыйммәтен киметү, аларны кирәгеннән артык тотуны бетерү, балансылык - көн бурычы.

Киңәшмәдә терлекчелек продукциясе һәм аны урнаштыру турындагы мәсьәлә дә кискен куелды.

Мин яңа гына республиканың Идел аръягы районнарында булып кайттым, диде Президент М.Шәймиев. Авыл кешеләре продукцияне сату проблемасыннан зарландылар. Мисал итеп ,ул йогурт сатудагы кыенлыкларны китерде. Бу продукт "Оргсинтез" акционерлык җәмгыятенең ярдәмче предприятиесендә җитештерелә һәм ул Казан базарына үтеп керә алмый. Чөнки анда чит илдән кертелгән . шундый ук продукция тулып ята. Илебез товар җитештерүчесенә булышу - бүгенге реформаның нигезе ул, дип дәвам итте Минтимер Шәрипович. Үз товар җитештерүчесен якламаган илне табып карагыз. Бүген базар өчен көрәшәләр генә түгел, ә сугышалар да. Кызганычка каршы, безнең илдә бу мәсьәләгә тиешле игътибар бирелмәде, шунлыктан бүген моның нәтиҗәләрен күрәбез.

Тапшырылган продукция өчен түләүне тоткарлаучы ит һәм сөт промышленносте, сәүдә җитәкчеләре кискен тәнкыйтькә дучар булдылар. Шәһәр сөт заводының монополиясенә чик кую максатында Казанда сөтне күпләп сату базарын булдырырга кирәк. Президент сөйләшүдә бик кискен булды: базарларга басым ясарга кирәк. Нервлары йомшак кеше эшли алмый бүген. Республика җитәкчелеге үз товар җитештерүчесен яклауга, продукцияне урнаштыру базарына контроль ясау мәсьәләләренә йөз белән борыла.

Киңәшмәдә "Татсельхозтехника", "Ашлык кабул итү һәм ашлык эшкәртү предприятиеләре" холдинг компанияләре президентлары М.Фәттәхов һәм Л.Хәмәдуллина, "Татнефтепродукт" холдинг һәм "Татагрохимсервис" генераль директорлары Р.Сабиров, С.Кәлимуллин һәм башкалар чыгыш ясады.

Республика прокуроры С.Нәфиев Татарстанның кием - салым, азык - төлек һәм вакытлы базарларында үткәрелгән рейдлар нәтиҗәсе турында сөйләде. Рейдлар үткәрү шуны күрсәтте: бу базарлардан керә торган гаять зур акча ташкыны бюджетка эләкми, чөнки базарлар криминаль структураларның ныклы контролендә. Шулай итеп, җирле хакимиятнең ваемсызлыгы аркасында бик күп тере акча читкә китә. Президент хокук саклау органнарына һәм хакимият башлыкларына бу хәлне ачыкларга, аны нормальләштерү өчен кичектергесез чаралар күрергә задание бирде.

Киңәшмәдә шулай ук пенсионерларга пенсияләр һәм бюджет өлкәсендә эшләүчеләргә эш хакы түләү, бюджетка акча керүне тәэмин итү кебек мөһим мәсьәләләр дә тикшерелде.

Пенсия фондында кайчандагыга караганда да авыр хәл килеп туды, диде республика башлыгы. Бүгенге көндә Пенсия фондына чигерүләр буенча Казан 62 процент, Зеленодол - 49, Чаллы һәм Алабуга - 24, Нурлат - 25, Азнакай - 20 процент кына җыйды, ә Тукай, Чирмешән, Мамадыш, Чүпрәле кебек авыл районнарының Пенсия фондына чигерүләре 5 - 6 процент кына.

Без Пенсия фондының яңа җитәкчелеге керткән тәкъдимне кабул итәргә мәҗбүрбез, диде М.Шәймиев. Бүгеннән башлап һәр төбәк, һәр шәһәр Пенсия фондына күпме акча кертә ала - пенсияне дә шулкадәр алачак.

Бик кырыс чара бу. Ул хакимият башлыкларын гына түгел, беренче чиратта, Пенсия фондына акча аз керә торган районнарда яшәүче пенсионерларны бик авыр шартларга куя. Ләкин дәүләт бюджетында акча булмаган шартларда үзләрендә җаваплылык сизмәүче җитәкчеләргә йогынты ясауның башка формасы юк. Беркайдан да ярдәм көтеп ятып булмый, диде М.Шәймиев. Бөтенесе өчен җирле җитәкчеләр җаваплы. Базар шартларыннан килеп чыга торган хәл әнә шундый.

Мәгариф хезмәткәрләренә эш хакы түләү буенча зур бурычлыбыз. Чаллы, Түбән Кама, Зеленодол, Югары Ослан районнары укытучыларга әле апрель өчен дә түләмәделәр. Финанс министрлыгы якын көннәрдә үзенең 82 миллион сумлык бурычын бирәчәк, әмма бурычларның зур күпчелеге җирле бюджетка бәйле. Кайбер районнарда бюджет нибары 50 - 60 процентка гына тулыландырыла.

Республикада кадрларны алмаштырып тору турында сөйләп, Президент моны нормаль процесс дип атады. Җитәкчеләргә таләпләрнең арта баруы турында тагын бер кат кисәтте: югары җаваплылык тоеп, заманча фикерләп, уңышларга ирешеп, каты хокукый кысаларда эш итәргә кирәк.

Киңәшмә барышында М.Шәймиев агымдагы вакыйгаларны яктыртуда, реформалар үткәрүдә массакүләм мәгълүмат чараларының роле турында кат - кат әйтте. Журналистларны эфирда һәм матбугатта һәр сүз өчен җаваплылыкка, оптимистик мисаллар аз булмаган тормышыбызны объектив яктыртуга чакырып, Татарстан Президенты матбугат белән ачыктан - ачык, хәбәрдар шартларда аралашу кирәклеген раслады.

**Киңәшмә эшендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Татарстан Республикасы Премьер - министры Рөстәм Миңнеханов катнашты.**

**(Татар - информ).**

**ЯҢАЛЫК**

## ПЕНСИОНЕРЛАРГА ҺӘМ ЯҢА ӨЙЛӘНЕШҮЧЕЛӘРГӘ ТАШЛАМАЛАР

Авиабилетларга бәяләр моңарчы булмаган дәрәҗәдә киметелде - Түбән Кама авиапредприятиесе җитәкчелеге татарстанлылар һәм республика кунаклары өчен әнә шундый сюрприз әзерләде.

30 сентябрьгә кадәр пенсионерлар өчен, 16 яшькә кадәрге инвалид балалар өчен һәм Бигеш Халыкара аэропортыннан Мәскәүгә, Анапа, Екатеринбург, Минводы, Сочи, Нежневартовск, Яңа Уренгой, Баку, Симферополь һәм Ташкентка очучы тупланган төркемнәр өчен авиабилет бәяләре ике тапкыр арзанрак булачак.

"Түбән Кама авиапредприятиесе" пассажирларның кайбер башка категорияләре өчен дә льготалы бәяләр кертте. Вузларда көндез торып укучы студентлар һәм курсантлар, гомуми белем учреждениеләрендә укучылар, Оборона һәм Эчке эшләр министрлыкларының вакытлы хезмәттәге хәрби хезмәткәрләре, санаторий - курортларга баручы кешеләр, инвалид баланы озатучы, шулай ук өч айдан күбрәк бергә яшәүче яңа өйләнешкән кешеләр бу маршрутлар буенча 30 процентлы ташлама белән оча алалар.

Пассажирларның үзләре белән алган йөкләре өчен түләүгә дә 20 процентлы ташлама кертелде.

**("Ватаным Татарстан"нан).**

**Икътисад, гуманитар фәннәр, җитәкчелек һәм хокук Көнчыгыш институтының Бөгелмәдәге вәкиллеге түбәндәге факультетларга студентлар кабул итә:**

*юридик, финанс-икътисад, тарих - филология, педагогика һәм психология, чит телләр, физкультура һәм спорт, социаль - мәдәни эшләр.*

Укулар читтән торып һәм түләүле. Түләүдә льготалар каралган. Кабул итү - имтиханнарсыз, тест нигезендә. Укуны бетергәч, дәүләти үрнәктәге дипломнар бирелә. РФ Югары белем дәүләт комитеты тарафыннан 1995 елның 24 маенда бирелгән 16 - 227 номерлы лицензия. РФ Гомуми һәм һөнәри белем бирү министрлыгында дәүләт аккредитациясе турында 1997 елның 17 декабрендә бирелгән 25 - 0109 номерлы таныклык.

***Адрес: Бөгелмә шәһәре, Я.Гашек ур., 10, тел.: 5-39-45, 3-46-61.***

# НУРЛЫ ЯК

**Г.СӘГЫЙРОВ**

### СОҢГЫ НУРЛАР

*... Кайтам әле...*
*Уч төбендә әнә -*
*Үз авылым тора күренеп.*
*Уйсулыкка төшеп җитсәң генә*
*Тирәкләргә кала күмелеп.*
*Өч ел буе йортым - җирем ятим.*
*Аена бер кайтып... киленем*
*күнмәде, лә...*
*Кайтыйм әле - кайтыйм:*
*Бик тынычсыз бүген күңелем.*
*Намаз укып яткач бүген иртән*
*Мин төшемдә күрдем картымны.*
*Йөзе - боек:*
*"Кайт инде, ди, көтәм.*
*Җигеп килдем җирән атымны".*
*Имеш- аның әле егет чагы.*
*Килгән, имеш , мине урларга.*
*Элеккедәй итеп, үзе тагы*
*Әй, тотынды сузып җырларга.*
*Әйләнермен бер*
*иркенләп йөреп.*
*Кирәк булса - эзләп табарлар;*
*Йорт хуҗаларына Ясин биреп,*
*Кайтырмын дим, укып намазлар.*
*Уф, йөрәгем... күкрәгемә*
*сыймый...*
*Әллә нишләп, китте бар хутым...*
*Янә туктап ял итмичә булмый*
*Үшәгендә яшел сарутның.*
*Йомшак кына...*
*бәрәннәргә... печән...*
*Күз алларын сара ак томан...*
*Сабый чагы...*
*Әнисе дә исән:*
*"Әйдә, балам,*
*калма артымнан..."*
*Ул - иярде... йөгерә... яланаяк...*
*Күктән иңгән нурга кушылып,*
*Күтәрелде биек - әллә кая!*
*Күгәрчендәй гүзәл кош булып...*
*... Чал чәчләрен сыйпап*
*җилләр исте.*
*Болыт үтте. Балкып ай чыкты.*
*Кичке нурлар саубуллашып үпте*
*Дисбе тотып яткан карчыкны...*

**М.УСМАНОВА**

### ...ТЫН ЗИРАТТА

*Кабер туфрагына башын куеп*
*Бер ир үкси тып - тын зиратта.*
*Ачы хакыйкатьтән, үкенечтән*
*Үксеп елый икән ир - ат та.*
*Туфрак астындагы анасыннан*
*Кичерүен сорап ялвара.*
*-"Вакыт җитми, Әни,*
*вафат булдың-*
*Үкенечтән чәчем агара.*
*Кичер мине,Әни! йөрәгеңә*
*Мин салдым бит авыр яраны.*
*Көтмәгәнсең назлап имезгәндә*
*Шундый булыр диеп балаңны.*
*Төннәрендә һәр көн*
*исереп кайтып*
*Акырып - бакырып сине уяттым.*
*Иртәләрен үләм махмырдан, дип,*
*Акча сорап сине йөдәттем.*
*Соңгы тиенеңне алып чыгып*
*Кибетләрдә тамак чылаттым.*
*Хәлсезләнеп*
*картлык көннәреңдә,*
*Әнкәй, Сине күпме елаттым?!*
*Улыбызны ташлап хатын китте*
*Түзәлмичә минем этлеккә.*
*Ә син, Әни, безне ташламадың ,*
*Көч табалдың, түздең ничек тә.*
*Әйтә идең, Әни:*
*"Акылны да , намусны да*
*хәмер югалта"*
*Исереп кайтып*
*пенсиямне сорап*
*Улым хәзер мине елата.*
*Күпме үгетләдең "кеше бул"-дип*
*Сабыр гына түзеп барсына.*
*Кичермәсәң, Әни,*
*мин нишләрмен*
*Кыямәт көн ходай каршында"*
*Кичер мине, Әни!..*

## ЯШЬЛЕК ЯЛКЫННАРЫНДА ЯНЫЙК ӘЛЕ БЕРГӘЛӘП

***Татлы телле, гүзәл сынлы бу мөлаем туташны мин күптәннән беләм. Ул вакытта без әле башлангыч класста укый идек. Безгә пионервожатый итеп өлкән сыйныфтан Фәридә апа Зиннәтуллинаны билгеләделәр. Ул үзенең активлыгы, фантазиягә бай үзенчәлекле кыз булуы белән аерылып тора. Тәнәфесләрдә аның артыннан бер адым да калмыйча тагылып йөри идек. Дәресләрдән соң да Фәридә апабыз, төрле уеннар оештырып, балалар белән аларга җырлар, биюләр өйрәтеп мәш килеп ята иде.***

***Гомер уза, еллар үтә. Инде мин дә мәктәп укучысы түгел. Каршымда да пионервожатый түгел, Самарадагы "Яктылык" дигән бердәнбер татар мәктәбенең алдынгы укытучысы, үзешчән композитор, шәһәрдәге "Ялкынлы яшьлек" эстрада ансамбленең җырчысы, концертларын алып баручысы утыра.***

> ***"Исә җилләр, үсә гөлләр,***
> ***Үтә көннәр нур чәчеп.***
> ***Агыла таңнар, ныгый җаннар,***
> ***Табыла даннар көрәшеп.***
> ***(Фәнис Яруллин).***



***Газетаны даими укучылар сүзнең Түбән Нурлат кызы Фәридә Зиннәтуллина турында барганын аңлаганнардыр инде. Бик еш булмаса да, ул ансамбль безнең якларга да килгәли бит. Әле менә быел Сабантуйда бар халыкны таң калдырып, искиткеч биюләре, дәртле җырлары белән сокландырып, кыскасы, рәхәтләндереп ял иттереп киттеләр. Берочтан авылыбызда да концерт куйдылар. Ярты төнгә кадәр сузылган тамашадан соң аларга рәхмәт әйтергә дип сәхнәгә менгән мәктәп директоры Т.В.Әюповның сүзләре истә калган:***

***- Безнең "капризный" Түбән авыл халкының клубка күптән болай күпләп җыелганы, концертларны болай яратып караганы, артист халкын болай ук үз итеп алкышлаганы юк иде...***



**- Фәридә апа, "Ялкынлы яшьлек"не башка якларда да беләләрме соң?**

- Бөтен Самара, өлкәдәге һәр авыл халкы ярата безнең коллективны. Болай да концертлар куеп йөрибез, һәр елны Сабантуйның да үзәгендә булабыз. Әле менә быелгы сабантуйда катнашмаска, ял итәргә уйладык та (ни әйтсәң дә, нәкъ шушы чакта күбебезнең чираттагы ялы һәм аны барыбызның да үз якларында үткәрәсе килә бит), халык моңа бик нык ризасызлыгын белдерде. Җитәкчебезгә ансамбльнең быелгы бәйгедә ни өчен катнашмавын мәйдан каршына чыгып аңлатырга туры килде.

Ә популярлыкка килгәндә, моннан 27 ел элек оешкан коллектив быел 500 нче концертын куйды. Гел яңартылып тора торган программаларыбыз белән әледән - әле гастрольләргә чыгабыз. Санкт - Петербургта 93нче елдан бирле ел саен концертлар биреп киләбез, Мәскәүдә, Уфада, Ульянда еш чыгыш ясыйбыз. Татарстан радиосында язмаларыбыз саклана, ә 1996 елда Казанда безнең ансамбль турында махсус фильм төшерелде...

**- Чыннан да, тарихыгыз бай, данызыгыз таралган икән. Ә шул тарихны тагын да баету, данызыгызны саклар өчен күп тырышырга туры килә торгандыр дип уйлыйм.Бу җәһәттән нинди кыенлыкларыгыз бар?**

-Иң авырткан мәсьәләбезне кузгаттыгыз.Хәзерге акча кытлыгы заманында спонсорлар булмаса, коллективыбыз яши алмас иде. Ә ул яктан без үзебезне бәхетле саныйбыз. Самарада андый шәхесләр аз түгел. Абруйлы җитәкче, көчле шәхес, Самара өлкәсеннән Дәүләт Думасында депутат, татарлар өчен җан атып яшәүче, милләтебез өчен тау - таш күчерергә әзер булган милләтпәрвәр Вәлиуллин Әхмәдулла улы Җәмил әфәнденең ныклы канаты астында көн күрәбез без. Бер генә мисал: безнең синтезаторыбыз - Рәсәйдәге иң шәп өч синтезаторның берсе. Шундый дәрәҗәле кеше булуына да карамастан, безнең белән шәһәрдән - шәһәргә йөрергә, мәшәкатьләребезне уртаклашып, проблемаларыбызны хәл итешергә вакыт таба ул. "Прогресс" һәм элемтә кабеле заводлары генераль директорлары Вәгыйзь әфәнде Мөхәммәтшин һәм Әнвәр әфәнде Кашаповка да бик рәхмәтле без.

**- Алар матди ягыгызны кайгыртса, ансамбльнең рухи тоткалары турында да әйтеп китегез инде.**

- Аны оештыручы да, шуннан бирле алыштыргысыз җитәкчесе, "йөрәге" булып Самара өкәсенең мәшһүр татары дигән лаеклы исем хуҗасы Илгиз абый Колючев тора. Рәсәйнең атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемгә ия бу кеше өчен ансамбль - бер хобби гына. Илгиз абый - механика заводында баш инженер, техник фәннәр кандидаты. Милләт өчен фидакарьлеге, ансамбльгә мәхәббәте шулкадәр көчле ки, шәһәр читендәге кысан гына хрущевкасыннан 10 - 15 километрны җәяүләп үтеп тә репетицияләргә йөри ул.

**- Әйе, Фәнис абый Яруллин дөрес әйткән шул:**

***Мал кирәкләр - мал таба,***
***Дан кирәкләр дан таба.***
***Ә җан өчен эшләүчеләр***
***Мал югалтып,дан югалтып,***
***Йөрәгенә ял таба.***

**Шундый сәнгатькәр җитәкчегез тирәсендәге фидакарь талантларыгыз турында да әйтеп китегез инде. "Ялкынлы яшьлек"нең исеме җисеменә туры киләме соң?**

-Ансамблебезнең составына килсәк, ветераннар белән алтмышлап җыелабыз. Арабызга гел яшьләр килеп тора. Күбебез үзешчәннәр. Дөрес, арада һөнәрмәннәр дә юк түгел. Радик Газизов, мәсәлән, Самара мәдәният институтын тәмамлаган профессональ баянчы. Хореографларыбыз да махсус белемле. Шулардан Гүзәл Саттарова куйган "Аккошлар" биюе бөтен Рәсәйне таң калдырды. Баянчыбыз Наил Нурмөхәммәтов монда ансамбль оештырылганнан бирле эшли. Аның Шәмсия Җиһангирова сүзләренә язылган "Әнкәй", "Туган авылым" җырларын барыбызның да ишеткәне бар. Иң популяр яшь җырчыларыбыздан Илнур Алтынбаев, Руфия Җиһангирова, якташыбыз Гөлфия Гайнетдинова, биючеләрдән Искәндәр Гатинны әйтеп китәр идем.

**- Үзегезнең дә ролегез кечкенә түгел бит. Аннары сез көйләр дә чыгарасыз, Фәридә апа...**

- Ансамбльгә сигезенче ел йөрим инде. Ә көйләрем, нигездә Тукай шигырьләрен гитарада уйнап карап чыга. Быел "Чаллы былбылы" конкурсында да шул җырларым белән катнаштым. Дүрт җыр белән барган идем, үземнең Тукай сүзләренә язган "Милләтчеләр" җырым белән дипломант булдым. Тамашачы аны якын кабул итте, уңышымны күреп, хәтта Салават кочаклап үпте үземне. Ә мин халык мондый "сәер" җырны кабул итмәс дип курыккан идем...

**- Чын сәнгать үз тамашачысын таба шул. Фәридә апа, сезгә дә, чит төбәктә телебезне, мәдәниятебезне, гореф-гадәтләребезне саклауда, татарларны берләштерүдә ансамблегезгә дә зур рәхмәт, иҗат ялкыныгыз киләчәктә дә сүнмәсен - сүрелмәсен, яшьлек кебек яшьнәп торсын, ялкын кебек дөрләп янсын.**

-Рәхмәт. Форсаттан файдаланып шуны да әйтим әле, озакламый, көзен "Ялкынлы яшьлек" Нурлатка тагын килергә җыена. Җыр сөюче, сәнгатьне яратучы, гомумән, рәхәтләнеп ял итәргә теләгән һәркемне концертларыбызга көтәчәкбез.

**Әңгәмәдәш -**
**Люция СӘЙФЕТДИНОВА,**
**КДУның журналистика факультеты талибәсе.**

**Рәсемнәрдә: Фәридә Зиннәтуллина һәм ансамбль артистлары Нурлат сабантуе сәхнәсендә.**

**Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ фотолары.**

**Редакциядән: Ә иртәгә кичке сәгать сигездә Нурлат мәдәният йортында танылган җырчылар Зәйнәп Фәрхетдинова белән Зөфәр Билаловның "Ак майларда ак вәгъдәләр" дигән яңа концерт программасы була.**

## *Нәниләргә укыгыз!*

**ӘЛФИЯ ХӘСӘНОВА.**
**Кычытканлы**

### Безнең әби

Безнең әби бар иде,
Кулъяулыгы ак иде,
Намазлыгы чиккән иде,
Дисбесе тезгән иде.
Әти - әниләр эштә,
Кайталар алар кичкә.
Әби ашлар пешерә,
Тәмле бәлеш тә мичтә.
Әбиләрне тыңладык,
Бәбиләрне йоклаттык,
Әбидән сорамыйча
Уйнарга да чыкмадык.
Әби картая бара,
Без гел үсеп торабыз,
Ерак - ерак болыннарга
Җиләккә дә барабыз.
Әй йөгерәбез аланга,
Яшел тугайлыкларга.
Чиләкләр дә бик тиз тулды
Кошлар сайрап торганда.
Әй кайтабыз, шатланабыз,
Тизрәк кайтыйк диеп.
Әби безгә каршы чыккан
Матур күлмәген киеп.
-Әби, әби, күп җыйдык!
Бүген җиләк күп булды,
Эре кызыл җиләк белән
Синең савыт та тулды!
-Әй, балам, рәхмәт яусын,
Бигрәк зурлагансың!
Минем кебек картайгач,
Урының түрдә булсын!..
...Әби безгә бүләк бирде
Яшел сандыгын ачып:
Чиккән сөлге, исле сабын,
Кулъяулык белән яулык.

### ПЕЧӘН ЧАБАМ

Җиләс таңда әткәй белән икәү
Печән чаба идек болында.
Әнкәй безгә чәй әзерли иде...
Күзне йомсам күрәм һаман да.
Кызу кояш сыга маңгай тирен,
Үлән арасында җиләкләр...
Шәһәр паркын чабучыны күрсәм
Кытыкланып куя беләкләр.
Әткәй күптән вафат, әнкәй чирле...
Яшьлегемдә калган ул заман.
Кызу көндә бөҗәк җырын тыңлап ,
Төшләремдә мин печән чабам.

***Наил Нәҗмиев.***
**Чаллы шәһәре**

# ЧУЛПАН "КАСКАДЕРЫ"

Хөрмәтле "Чемет"! Соңгы вакытта без, сине көтеп алучылар, газета битләрендә үзеңне сирәк күрәбез. Дөньяның кирегә китүе сәбәптер, бәлки, моңа.

Мин сиңа шушы көннәрдә "Чулпан авылында ачылачак "каскадерлар" мәктәбе турында сөйлисем килә.

Шул авылда яшәүче Гыйбадуллин Минәхмәт бу мәктәпнең беренче укучысы, хәтта тренеры да була ала. Ник дисеңме?

Бер көн шул 1нче кандидат исерек хәлдә һәм дәүләт номерлары да булмаган мотоциклга утырып Нурлатка килә. Шунда ук югары класслы трюкларын да күрсәтә башлый. Тимер юл кичүенә җиткәч, бөтен юл хәрәкәте кагыйдәләренә төкереп, ВАЗ автомашинасының "09" моделендә баручы ГИБДД начальнигын куып тотып узарга ниятли.

Кичүдә дежурда торучы бу хәлне күреп аз гына аңын югалтмый кала.

ГИБДД начальнигы да 25 еллык хезмәтендә мондый галәмәтне беренче тапкыр күреп, хәлне ачыкларга тели. Мотоциклын туктатырга дигән законлы таләпкә каршы безнең "герой" тагын да тәвәккәлрәк адымга күчә: арткы көпчәкләрендә тимер юл буенча элдертә. Шундый куркыныч трюкны тимер юлчыларның да күргәне булмаган икән, хәтта. Аны хәзерләүләр конторасы янындагы куаклар арасында эзләгән арада, "трюкач"ыбыз аэропорт янында була инде.

Тик аннан да качып котыла алмады, кемдер аны эчке эшләр бүлегенең дежур частена китерде. Тәвәккәл трюгы өчен ул 10 тәүлеккә кулга алынды һәм 668 сум күләмендә штраф түләргә мәҗбүр ителде.

**А.КАЮМОВ,**
**ГИБДДның юл күзәтчелеге дәүләт автоинспекторы.**

ИДЕЛ БУЕНДА



Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ
фотоэтюды

***Р.САФИНА***

## *АҢЛАМЫЙСЫЗ*

*Һәрчак шат күңелле дисез,*
*Яшисең кайгыларсыз.*
*Күңелемдәге сагышларны*
*Күрмисез, ялгышасыз.*
*Сагышлар авыр булса да,*
*Эчкә йотам , сиздермим.*
*Җаным борчуга тулса да*
*Дусларымны биздермим.*
*Син гел көләч йөзле, дисез,*
*Юк синең моңың - зарың.*
*Юк минем көләч хәлдә дә*
*Кайгыдан аерылганым.*
*Өзгәләнәм, тик беркайчан*
*Сыгылмам сагышлардан.*
*Язмыш уйный, мине сыный,*
*Аерылалмыйм сагышлардан.*

● *Комбайнчы игътибарына*

01

# КОМБАЙНЧЫ, МЕХАНИЗАТОР ҺӘМ...УТ

Бүген безнең кырларда төрле модификациядәге комбайннар эшли. Кыйммәтле техниканы саклау өчен янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен белү һәм үтәү дә мөһим . Ә янгын төрле очракларда килеп чыгарга мөмкин:

- машина двигателе торбаларыннан очкыннар чыкса;
- двигательнең төтен чыгару системасы тыгыз беркетелмәгәнлектән очкыннар чыкса;
- машина детальләренә артык җылынган ягулык һәм май кебек техник продуктлар эләксә;
- суктыру һәм үлчәгеч җайланмаларына каты предметлар бәрелгәндә;
- электр җайланмалары төзексез эшләгәндә (кыска ялганыш һ.б.);
- машина детальләре югары температурага кадәр җылынса.

Ашлык культуралары урып - җыю чорында аеруча янып китүчән. Вак масса җил белән капот астындагы бушлыкка кереп, 300 - 500 градуска кадәр җылынган детальләргә тия һәм шунда ук коры саламга ут кабарга мөмкин. Мондый очракта янгын чыкмасын өчен двигатель тирәләрен һәм капот астындагы бушлыкны даими рәвештә чистартып торырга; көндәлек техник хезмәт күрсәткәндә комбайнны ашлык сабакларыннан арындырырга; гамәлдән чыккан детальләрне үзвакытында ачыклау өчен һәрдаим тикшереп торырга һәм башка таләпләрне үтәргә кирәк. Гадәттә эшләп торучы комбайннарда ягулык агып чыгарга мөмкин, карамыйча торганда ул детальләрне, комбайн узелларын томалый. Аларга ут капса, ул тиз арада машинаны ялмап ала һәм еш кына мондый янгынны сүндереп булмый.

Янгыннан саклану максатында комбайннар икешәр ут сүндергеч, көрәк һәм пумала белән комплектланган булырга тиеш. Әгәр дә янгын чыга калса, комбайнның молотилкасын сүндерергә һәм мөмкин булса, аны иген җиреннән алып чыгарга тырышырга кирәк, аннары двигательне, аккумулятор батареяларын сүндерергә һәм утны сүндерә башларга кирәк. Моның өчен, беренче чиратта, ут сүндергечләрне куллану мөһим, аннары утка тукыма капларга яки су сибәргә кирәк. Двигатель янганда ут сүндергечтән күбекне астан сиптерү нәтиҗәлерәк, сүндергәннән соң да янган урынга ком яки туфрак сибеп калдыру мөһим.

**Н.ЗАХАРОВ,**
**Нурлат янгын часте начальнигы.**

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Иң кадерле кешебез, **әниебез Роза Шәфигулла кызы Билданованы** туган көне белән котлыйбыз. Нык сәламәтлек, озын гомер, тыныч, тигез тормыш телибез.

Көләч йөзләреңне алсулатып,
Нур балкышы иңгән йөзеңә.
Теләкләрнең иң изгесен генә
Әйтик әле бүген үзеңә.
Үткән еллар җиңел булмаса да,
Канәгатьлек хисе кичереп.
Киләчәгең тигез, матур булсын
Бәхет гөлләренә күмелеп.

**Иң изге теләкләр белән**
**тормыш иптәшең, балаларың.**


## БЕЛДЕРҮЛӘР

## САТАБЫЗ

**Чистай шәһәрендә йорт.** Нурлатта тел.: 2-18-49.

***

**"Урал" мотоциклы.** Тел.: 2-24-46.

***

**Ашыгыч төстә Тукай урамында 31нче йорт.**

***

**Өч бүлмәле фатир, ВАЗ - 2121, чистарту корылмалары артында гараж.** Адрес: К.Маркс ур., 2- 15.

***

**Завод тыкрыгында бер бүлмәле фатир.** Адрес: Чернышевский ур., 3.

***

**Чанада 4 х 5 ле гараж.** Тел.: 5-30-70.

***

**Гагарин урамында өч бүлмәле фатир һәм капиталь гараж**. Тел.: 2-19-85.

***

**Йөрмәгән яңа УАЗ - 31514 ( люгы бар, күперләре редукторлы, көрән - зәңгәр төстә), бәясе килешү буенча.** Тел.: 2-20-42.

***

**1994 елның августында чыккан, кулланылышта булган бик әйбәт хәлдәге әрҗәле ГАЗ - 3307, кыйммәт түгел.** Адрес: Тукай ур., 29.

***

**Каравыл Тавы тирәсендә дача (МСО), 10 литрлы һәм җылылык көйләгечле электроколонка, кыйммәт түгел**. Адрес: Мәскәү ур., 15 - 2, тел.: 2-24-70, 2-14-22.

***

**Көнчыгыш микрорайонында нигезе белән участок**. Тел.: 5-17-99.

***

**Кузовы 1995нче слда, двигателе 1997 елда алыштырылган1974 елгы ВАЗ - 2106**. Тел.: 5-20 -13.

***

**Совет ур., 49-1 адресы буенча йорт.** Тел.: 2-24-58.

***

**Суворов урамында 41нче йорт.** Көндезге 2дән кичке 8гә кадәр мөрәҗәгать итәргә.

***

**Шәһәр үзәгендә 2 бүлмәле фатир.** Тел.: 5-22-03.

***

**Әйбәт хәлдәге ВАЗ - 2103.** Яңа Иглайда Илшат Хөсәеновка мөрәҗәгать итәргә, тел.: 2-36-11.

## САТАБЫЗ, АЛМАШТЫРАБЫЗ

**Көнчыгыш микрорайонында төзү материаллары белән төзелеп бетмәгән кирпеч йорт, ике бүлмәле фатирга да алмаштырырга була.** Адрес: Совет ур., 92 - 8

***

**Ике бүлмәле фатирны - өстәмә түләп бер бүлмәлегә. Гаражы, ике сарае, ике бакчасы бар. Яки сатабыз.** Адрес: Завод ур., 5 - 15.

## БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА. БЕЛДЕРҮЛӘР

***Мөгезле эре терлек асраучы Нурлат халкы игътибарына!***

7нче августта Линейная урамы, 38 адресы буенча ветдәвалау станциясендә терлекләр туберкулездан, бруцеллездан, лейкоздан тикшерелә, аларга себер язвасына һәм эмнорга каршы профилактика прививкалары ясала. Малларны алып килү мәҗбүри! Шунсыз хуҗалыкларга продукцияләрен сатарга рөхсәт бирелмәячәк.

Нурлат райпосының азык - төлек комбинаты халыктан авыл һәм шәһәр сәүдә челтәре аркылы пыяла савыт - саба кабул итә.

0,650 граммлы банкалар - 30 тиеннән,

0,250 граммлы майонез банкалары - 15 тиеннән.

**Белешмәләр өчен тел.: 2-21-15.**

***Пенсионерлар игътибарына!***

**"Нурлат ит комбинаты"** ачык акционерлык җәмгыяте Гыйматдинов ур., 52 адресы буенча пенсионерларга ит комбинаты продукциясен **пенсия хисабына** җибәрә. Ит продуктлары һәм казылык әйберләренең киң ассортименты бар.

Үзең белән паспорт һәм пенсия кенәгәсе алып килергә кирәк. Кибет иртәнге 8дән кичке 6га кадәр ял көннәрсез эшли. Әбәт вакыты көндезге 1дән 2гә кадәр.

**Администрация.**

***"ФИСКО"*** фирмасында төзелеш материалларына заказ биргән, шулай ук мең данәсен 1300 сумнан Чабаксардан кайтарыла торган берьярымлык кызыл кирпеч, Чабаксарда фатир сатып алырга теләүче дәүләт предприятиеләре, АҖ һәм шәхси затларның Татарстан Республикасындагы тышкы сәүдә вәкиллегенә шалтыратуларын сорыйбыз.

**Тел.: 5-22-37.**

***Идел Буе региональ наркология үзәге***

*Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.*

***Табиб М.Б.Багрянцев.***

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга 14нче һәм 28 нче август көннәрендә, көндезге сәгать 11дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ Сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.



БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

**Учредительләр: Нурлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.**
**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2353 данә. **3211.**